**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 35 "28" август 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 48 һәм 49 статьялары нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс игълан итәргә һәм аны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 2010 елның 13 октябрендәге №4 карары белән расланган Нигезләмәгә яраклы рәвештә үткәрергә.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына дәгъва итүчеләрдән конкурска документларны кабул итү 2018 елның 31 августыннан 2018 елның 20 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча башкарыла: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Актүбә шәһәр тибындагы поселогы, Губкин урамы, 24 нче йорт, 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр, төшке аш 12 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр, көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Тел.: 3-20-65, 3-12-70, факс: 3-16-63.

2. Конкурс комиссиясе 2018 елның 21 сентябрендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча үткәреләчәк: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Актүбә шәһәр тибындагы поселогы, Губкин урамы, 24 йорт һәм кандидатлар турында мәгълүматны, конкурс нәтиҗәләрен Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советына бирергә.

3. Кушымтага яраклы рәвештә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатларны карау өчен 3 кешедән торган Конкурс комиссиясе составын расларга.

4. Әлеге карарны рәсми матбугат басмасында - «Маяк» газетасында, 2018 елның 31 августыннан да соңга калмыйча, бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakyevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Р.А. Галиева

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына 2018 елның «28» августындагы 35 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны билгеләү өчен конкурс комиссиясе составы

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Галиев<br>Роза Алмас кызы | 7 нче сайлау округы депутаты, Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башлыгы |

*Комиссия рәисе урынбасары:*

| | |
|---|---|
| Сучков<br>Андрей Николаевич | 4 нче сайлау округы депутаты, “Азнакайнефть” "НГДУның 3 нче ЦДНГ начальнигы |

*Комиссия секретаре:*

| | |
|---|---|
| Ганиев<br>Рәдис Атлас улы | 1 нче сайлау округы депутаты, “Транс-Авто” ЖЧЖ директоры |